БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 август 2024 ел №267

**Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2016 елның 23 декабрендәге 68 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, 2022 елның 14 мартындагы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 60-ФЗ номерлы Федераль законга, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына, Татарстан Республикасының 2023 елның 26 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 1-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 3 февралендәге 2-ТРЗ номерлы законнарына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына нигезләнеп Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2016 елның 23 декабрендәге 68 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2017 елның 24 июнендәге 88 номерлы, 2018 елның 1 ноябрендәге 151номерлы, 2020 елның 09 октябрендәге 10 номерлы, 2022 елның 18 январендәге 100 номерлы, 2023 елның 27 апрелендәге 186 номерлы, 2023 елның 09 августындагы 204 номерлы, 2023 елның14 декабрендәге 227 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Нигезләмәнең 29 статьясының 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм муниципаль хезмәткәр булган вакыт аралыгында граждан тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

2) Нигезләмәнең 29 статьясындагы 11 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11.1 пункты өстәргә:

11.1) дәүләт сере булып торган белешмәләргә билгеләнгән рәвештәге рөхсәтне рәсмиләштерү; ».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://baltasi.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы
башлыгы урынбасары,
Балтач район Советы рәисе урынбасары — Н.Н. Сабирҗанов